ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планын расларга (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2015 елның 10 ноябре
№ 917-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2015 елның 10 ноябрендәге
917-V ДС номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәре | Гамәлгә ашыру буенча чаралар | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Иң катлаулы мәсьәләләрне хәл итү социаль-сәяси тотрыклылык һәм иҗтимагый бердәмлеккә ирешкәндә генә мөмкин булачак. | 1.1. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән үзара эшчәнлек буенча эшне дәвам итү:<br>– Татарстан Республикасының карала торган барлык закон проектларын Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына җибәрү;<br>– Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары утырышларында һәм закон проектларын әзерләү буенча эшче төркемнәр составында катнашуларын тәэмин итү. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 2. | Сәяси партияләрнең, беренче чиратта, парламент сәяси партияләренең муниципаль дәрәҗәдә вәкиллекләре саны артты. Актив гражданлык позициясендә торучы яңа депутатлар күп. Бу, һичшиксез, муниципалитетлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итәргә тиеш. | 2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округларындагы эше, җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары эшендә катнашуы.<br>2.2. Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы белән актив үзара эшчәнлектә җирле үзидарә мәсьәләләрен хәл итү буенча эшләр | ел дәвамында<br><br><br><br>ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары<br><br>Хәбибуллин А.Г. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Сайлау алды кампаниясе вакытында яңгыраган барлык тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне системалы анализлап, аларны тормышка ашыруга юнәлтелгән чаралар эшләргә кирәк.<br>Сайлау йомгакларын республикадагы тулаем хакимият системасына бәя бирү һәм башлаган үзгәртеп кору эшләрен дәвам итәргә күрсәтмә буларак кабул итәм. | оештыру, аның президиумы утырышларында катнашу.<br>2.3. Татарстан Республикасында “Бердәм Россия” Бөтенроссия сәяси партиясе депутат берләшмәләренең (фракцияләрнең һәм төркемнәрнең) Республика координация советы эшен булдыру һәм оештыру.<br>2.4. КПРФ исемлеге буенча сайланган Татарстан Республикасының барлык дәрәҗәдәге депутатлары эшен координацияләү буенча гомумрегиональ һәм зона киңәшмәләре. | ел дәвамында<br><br>ел дәвамында | Камалтынов Ю.З.<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе әгъзалары |
| 3. | Ирешелгән уңышларыбызның иң кыйммәтлесе – милләтара һәм динара татулыкка һәм тынычлыккаирешү.<br>Мәдәни-тарихи традицияләргә тирән хөрмәт хисе, республикада яшәүче барлык халык вәкилләренең үзара файдалы хезмәттәшлеге хәзерге Татарстанның аерылгысыз бер өлеше булып тора.<br>Әлеге мөнәсәбәтләрнең уңай характерда булуы илебез Президенты Владимир Владимирович Путин тарафыннан күп тапкырлар билгеләп үтелде.<br>Төрле милләт вәкилләре катнашкан хәрәкәт республикада көннән-көн активлаша һәм ныгый бара. Моңа дәүләт милли сәясәте программалары чараларының тулы күләмдә тормышка ашырылуы булышлык итә. Бөтендөнья | 3.1. Парламентара эшчәнлек кысаларында милли сәясәтне гамәлгә ашыру, милли иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары белән тәҗрибә уртаклашу. | ел дәвамында | Вәлиев Р.И. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | татар конгрессы, Рус милли-мәдәни берләшмәсе, Татарстан халыклары ассамблеясе эшчәнлегенә зур игътибар бирелә.<br>Республикада төрле милләт вәкилләре хәрәкәтенең инфраструктурасы да камилләштерелә. Казанда, Чаллы, Тәтеш, Түбән Кама, Менделеевск һәм Нурлатта халыклар дуслыгы йортлары эшләп килә. Лениногорск һәм Алабуга шәһәрләрендә шундый йортлар ачарга әзерләнәләр.<br>Болар барысы да муниципаль берәмлекләр башлыкларының этно-мәдәни эшнең ресурслар базасын формалаштыруга җитди каравына һәм милли иҗтимагый берләшмәләр белән нәтиҗәле хезмәттәшлегенә мисал булып тора.<br>Безгә гомуми федераль проектларда катнашу өчен Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык мөмкинлекләреннән активрак файдаланырга кирәк. | | | |
| 4. | Безнең өчен тагын берничә бик мөһим мәсьәлә бар, болар – милли белем бирүне үстерү, милли мәдәниятләргә ярдәм итү, туган телне саклап калу һәм үстерү.<br>Моңа аеруча игътибар бирергә, бу өлкәдә эшләвебезне киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк.<br>Тел милләтне берләштерә, халыкның рухи байлыгын туплый, аның тарихи хәтерен ныгыта. | 4.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында “Татарстан Республикасында милли белем бирүне үстерү концепциясе проекты турында”гы мәсьәләне карау. | 2016 елның феврале | Вәлиев Р.И. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Мәдәният өлкәсендәге уйланылган сәясәт республиканың эзлекле үсешендә аерылгысыз шарт булып тора.<br>Әдәбият елы кысаларында без бик күп иҗади кичәләр, очрашулар уздырдык, Боратынский һәм Горький музейларында төзекләндерү һәм экспозицияне яңарту эшләрен тәмамладык.<br>Музейларга, театрларга, клубларга халык теләп йөрергә тиеш.<br>Яшьләрнең тарихи-мәдәни мираска хөрмәт белән каравы, аны яратуы, белүе һәм дәвам итүе бик тә мөһим.<br>Бу мәсьәләдә Лев Толстой исемендәге музей-мәгърифәти үзәк ачу проекты алга зур адым булачак.<br>Яңа эш ысуллары Габдулла Тукай, Нәҗип Җиһанов, Галия Кайбицкая, Хәсән Туфан һәм башка күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләренең музейлары һәм мемориаль комплекслар эшчәнлеген активлаштырырга тиеш.<br>Моннан тыш, Татарстанның мәдәни брендлары, безнең авторлар әсәрләре республикадан читтә тиешле дәрәҗәдә танылган дип әйтеп булмый әле.<br>Без дөньякүләм мәдәни мәйданга мөмкин булганча күбрәк үтеп керергә тиешбез.<br>“Татар музыкасы җәүһәрләре”нә охшашлы проектларны әдәби иҗат һәм рәсем сәнгате өлкәсендә дә булдырырга кирәк.<br>Бу – мәдәният учреждениеләре белән беррәттән, иҗат берлекләренең дә бурычы. | 5.1. “Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” темасына хөкүмәт сәгате. | 2016 елның феврале | Вәлиев Р.И. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6. | Рухи яңарыш Татарстанда иҗтимагый үсешнең мөһим факторы булып тора. Республикада гыйбадәт йортлары торгызыла һәм яңалары төзелә, Изге Болгар Җыены, “Алексеевскида кыңгырау чыңы” һәм “Иман музыкасы” кебек социаль-мәдәни проектларга зур ярдәм күрсәтелә. Һәр ел саен татар дин әһелләре һәм православие җәмәгатьчелеге форумнары үткәрелә. Яһүд җәмәгатенең Казан синагогасына 100 ел тулуга багышлап уздырган чаралары уңай кабул ителде һәм киң яңгыраш тапты.<br>Болгар шәһәрендә илебезнең төп мөселман оешмалары тарафыннан кабул ителгән Җәмгыятькә хезмәт итү доктринасы зур иҗади мөмкинлекләргә ия.<br>Җитәкчелек итү миңа ышанып тапшырылган “Россия – ислам дөньясы” стратегик күзаллау төркеменең яңадан эшли башлавы хезмәттәшлек өчен тагын да киңрәк мөмкинлекләр тудырачак.<br>Без алга таба да илебездә дини белем бирү системасын камилләштерү юнәлешендә хезмәт куячакбыз.<br>Илебез Президенты В.В. Путин кушуы буенча төзелә торган Болгар ислам академиясе әлеге эштә зур роль уйнарга тиеш.<br>Шул ук вакытта безгә Казан Руханилар академиясен торгызу эшен активлаштыру зарур.<br>Дини белем бирү системасында | 6.1. “Татарстан Республикасында дини белем бирүнең торышы һәм перспективалары” темасына “түгәрәк өстәл”. | 2016 елның марты | Вәлиев Р.И. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | халыкның этник-конфессиональ составына мөмкин булганча игътибар итәргә кирәк. Татарстан халкы һәм, иң беренче чиратта, балалар барлык традицион диннәр белән таныш булырга тиеш. Бу исә иҗтимагый бердәмлек һәм татулык, ышаныч мөнәсәбәтләре урнаштыру өчен нигез булып тора.<br>Шул ук вакытта дин ярдәмендә республикабызга радикаль карашлар, экстремистлык күренешләре алып керергә тырышучылар үзләрен иң кискен каршылык чаралары көтәчәген белеп торсыннар. | | | |
| 7. | Ветераннарыбызга ярдәм итүгә, беренче чиратта, аларга социаль-медицина хезмәте күрсәтүгә, торак-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүгә аеруча зур игътибар бирелде.<br>Сугыш каһарманнары һәм тыл хезмәтчәннәренең исемнәрен мәңгеләштерү буенча да күп эш башкарылды. Һәр торак пунктта һәйкәлләр һәм истәлекле урыннар яңартылды, күп кенә мәктәпләргә батырлар исемнәре бирелде, аларда музейлар ачылды, эзләнү эше киң җәелдерелде.<br>Һичшиксез, бу эшне без дәвам итәчәкбез. Яшь буынга патриотик тәрбия бирү – дәүләт алдында торган мөһим сәяси, әхлакый һәм мәдәни бурыч.<br>Без туган җиребезнең, республикабызның, күпмилләтле | 7.1. “Сугыш чоры балалары турында” федераль закон проектын әзерләү һәм аны закон чыгару инициативасы сыйфатында кертү. | 2016 елның I кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе әгъзалары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Россиянең чын патриотларын тәрбияләргә тиеш. | | | |
| 8. | Законнарга үзгәрешләр керү һәм яңа вәкаләтләр нигезендә якын арада безгә иҗтимагый хәрәкәтнең төп вәкиллекле һәм координацияләү үзәге булган республика Иҗтимагый палатасының яңа составын расларга кирәк булачак. | 8.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары кандидатураларын карау һәм раслау. | 2015 елның декабре | Яһудин Ш.Ш. |
| 9. | Хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар һәм территориаль иҗтимагый үзидарәләр хакимият һәм халык арасындагы үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәле механизмы булып тора. Әлеге институтларны алга таба да үстерергә кирәк.<br>Болар республикада яшәүче һәркемгә балалар өчен уен мәйданчыклары һәм спорт мәйданчыклары төзү, машина кую урыннарын тәртипкә китерү, өй яны территорияләрен электр белән яктырту һәм анда агачлар утырту, төрле чаралар уздыру кебек әһәмиятле мәсьәләләрне чишүгә шәхси өлеш кертү мөмкинлеге тудыра. | 9.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында Татарстан Республикасында территориаль иҗтимагый үзидарәләр (ТИҮ) булдыру турындагы мәсьәләне карау. | 2016 елның II кварталы | Хәбибуллин А.Г. |
| 10. | “Халык контроле” системасы халык белән аралашуның сыналган һәм нәтиҗәле чарасы булып тора. Быел анда “коррупциягә каршы көрәшү” дигән яңа юнәлеш барлыкка килде.<br>Алга таба да барлык коррупциячел күренешләргә каршы көрәшүдә тәвәккәл эш йөртергә ниятебезне белдереп, без республикада яшәүче һәркемнең, дәүләт | 10.1. Татарстан Республикасы юстиция министры мәгълүматы буенча “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында”гы мәсьәләне карау .<br>10.2. Мошенниклык һәм коррупциячел схемаларны гамәлгә ашыруга китерүче | 2016 елның мае<br><br>2016 елның I кварталы | Яһудин Ш.Ш.<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | һәм муниципаль хакимият органнары, күзәтчелек һәм хокук саклау структуралары җитәкчеләренең ныклы һәм принципиаль позиция алачагына өмет итәбез. | бушлыкларны бетерү максатында “Гражданнарның кредит кулланучылар кооперативлары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү. | | Советы депутатлары – КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе әгъзалары |
| | | 10.3. 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының коррупциягә каршы программасы чараларын үтәү. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты |
| | | 10.4. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе |
| | | 10.5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыруда практик ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнарына чыгып катнашулары. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 11. | Халыкара һәм төбәкара элемтәләрне үстерү торган саен зур әһәмият ала. | 11.1. 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка дәүләтләр, Россия Федерациясе субъектлары парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлеге планын гамәлгә ашыру. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты |
| | | 11.2. Идел буе федераль округының Закон чыгаручылар ассоциациясе координаторы буларак Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе эшчәнлеген тәэмин итү. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 12. | Безгә актив рәвештә Татарстанның югары технологияле компанияләренең | 12.1. “Татарстан Республикасы икътисадына чит ил инвестицияләрен җәлеп | 2016 елның октябре | Борһанов Р.Т. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дөнья базарларына чыгуына һәм бизнесның халыкара икътисадый кооперациядә катнашуына ярдәм итү зарур.<br>Без шулай ук Россиягә кергәндә чит ил компанияләре үз идеяләренә һәм технологияләренә, бизнесына этәргеч бирү өчен безнең республиканы старт мәйданчыгы итеп сайлавын телә идек. | итү өчен уңайлы шартлар булдыру турында" темасына "түгәрәк өстәл". | | |
| 13. | Бүгенге көндә югары уку йортларының мәгариф оешмалары булудан тыш, җитештерү процессын фәнни яктан оештыру өчен предприятиеләребезнең партнерлары булуы да бик мөһим.<br>Башка төбәкләрдән һәм чит илләрдән югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итү белән бергә, әлеге белгечләрне үзебездә әзерләүгә дәүләт заказы булдыруга аеруча игътибар бирергә кирәк. Урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар киләчәктә эш белән тәэмин ителәчәкләрен тәгаен белсеннәр. | 13.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында "Кадрларның квалификациясен күтәрү буенча чаралар турында һәм аларны авыл хуҗалыгы өлкәсенә эшкә урнаштыру хакында"гы мәсьәләне карау. | 2016 елның феврале | Һадиев Т.Г. |
| 14. | Безнең бурыч – эшкуарлар өчен уңайлы мохит тудыру. Муниципаль сәнәгать мәйданчыкларыбыз зур мөмкинлекләргә ия.<br>Сәнәгать мәйданчыкларын барлык муниципалитетларда да оештырырга кирәк!.. Без бизнеска булышлык итүнең барлык төр программаларын да тормышка ашыруны дәвам итәчәкбез. Яңа оештырылган Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль | 14.1. "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең сәнәгать мәйданчыкларын үстерүнең проблемалары һәм перспективалары" темасына "түгәрәк өстәл" (муниципаль берәмлекләрнең берсе мисалында). | 2016 елның мае | Борһанов Р.Т. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | корпорациясе белән тыгыз хезмәттәшлектә икътисадның әлеге секторын масштаблы рәвештә техник яңартуны оештыру буенча тәкъдимнәр эшләргә кирәк. | | | |
| 15. | Авыл хуҗалыгы сәнәгать комплексы өлкәсендә икътисадны үстерүгә булышлык итүче барлык резервларны да тулы күләмдә файдаланырга кирәк.<br>Соңгы биш ел авыл хуҗалыгы өчен җиңелләрдән булмады. Табигать шартларының начар булуы белән бергә, әлеге тармакның үсешендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең кредитларны күп алуы, хуҗалык итүнең кече формалары вәкилләренең кредитларга көче җитмәве җитди йогынты ясады. Моннан тыш, эшкәртү егәрлегенең нәтиҗәсезлеге, логистикадагы кытлык өстәмә бәянең югары күләмен формалаштырырга мөмкинлек бирми.<br>Тармакка җитди ярдәм күрсәтелсә дә, бер үк шартлардагы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең эшчәнлек нәтиҗәләлеге бер-берсеннән нык аерыла.<br>Моннан тыш, агросәнәгать комплексы программаларына күрсәтелгән дәүләт ярдәмен файдалануның нәтиҗәлелегенә системалы анализ ясалмый һәм ул контрольдә тотылмый. Кайбер агрокомплексларның бөлгенлеккә төшүе – моның ачык мисалы.<br>Агросәнәгать комплексы өлкәсендә | 15:1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты һәм “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында “2015 елгы һәм пландагы 2016 елның I кварталына “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын үтәү йомгаклары турында” гы мәсьәләне карау.<br>15.2. Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәмен күрсәтүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларының максатчан файдаланылуын тикшерүне уздыруга Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә әзерләү.<br>15.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе утырышында “Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең проблемалары турында. Аларны чишү юллары” мәсьәләсен | 2016 елның гыйнвары<br>2016 елның IV кварталы<br>ел дәвамында | Һадиев Т.Г.<br>Якунин Л.А.<br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – КПРФның Татарстан |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | безнең төп бурыч – әлеге тармакка кертелгән акчаның нәтиҗә китерүен арттыру.<br>Тулаем алганда, агросәнәгать комплексында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрдән алып сату челтәрләренә кадәр бәя куюда катнашучылар арасында җир, мөлкәт һәм институтциячел мөнәсәбәтләрне җайга салырга, чит илләрдән товарлар кертүгә чикләүләр урнаштырылу шартларында үзебездә җитештерелгән продукцияне эшкәртү, саклау һәм сату мәсьәләләрен эшләргә, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне файдалануны контрольдә тотуның нәтиҗәле системасын кертергә кирәк. | карау. | | Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе әгъзалары |
| 16. | Икътисад хезмәт ресурсларының тигез үсешеннән башка алга китә алмый.<br>Зур инвестиция проектларын тормышка ашырганда без җитештерү өлкәсендә эшләүчеләргә кытлык проблемасы белән очраштык инде.<br>Башка төбәкләрдән һәм чит илләрдән югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итү белән бергә, әлеге белгечләрне үзебездә әзерләүгә дәүләт заказы булдыруга аеруча игътибар бирергә кирәк. Урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар киләчәктә эш белән тәэмин ителәчәкләрен тәгаен белсеннәр. Бу бурычны халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хәл итәргә тиеш. Алар үз | 16.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында “Яшьләрне һөнәри юнәлеш һәм эшкә урнаштыру буенча эшчәнлекне оештыру өлешендә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыру турында”гы мәсьәләне карау.<br>16.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында “Авыл хуҗалыгы өлкәсендә кадрларның квалификациясен күтәрү һәм аларны эшкә урнаштыру чаралары турында”гы мәсьәләне карау. | 2016 елның апреле<br><br><br><br><br><br>2016 елның феврале | Захарова С.М.<br><br><br><br><br><br>Һадиев Т.Г. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәтенә яңача караш булдырып, төп игътибарны һөнәри билгеләнешкә юнәлтергә тиеш.<br>Квалификацияле белгечләр әзерләүдә төп урынны ресурс үзәкләре алып тора. Шундый 5 үзәк эшли. Ел ахырына тагын 9 үзәк – “Татнефть” компаниясе белән берлектә Түбән Кама һәм Лениногорск шәһәрләрендә, Челтәр компаниясе белән берлектә Зәйдә, Горький исемендәге завод һәм “Позис” заводлары белән берлектә Зеленодольск шәһәрендә, Казан халыкара аэропорты белән берлектә Лаешта ачылырга тиеш. Әтнә һәм Мамадыш районнарында аграр юнәлештәге 2 ресурс үзәге, Казан шәһәрендә автотранспорт юнәлешендәге ресурс үзәге эшләячәк. | | | |
| 17. | Соңгы елларда мәгариф системасында – балалар бакчаларыннан алып югары уку йортларына кадәр – матди базаны ныгыту буенча да күп эш башкарылды.<br>Россия Федерациясе Президентының май аенда кул куелган указларын үтәү барышында мәгариф өлкәсендә хезмәт хакы конкурентлыкка сәләтлелек дәрәҗәсенә күтәрелде. Без конкрет нәтиҗәләр көтәргә хаклы.<br>Һәр дәрес, һәр лекция кызыклы булырга, тәрбия һәм белем бирү максатларына хезмәт итәргә тиеш.<br>Хөкүмәтебез һәм муниципалитетлар башлыкларына мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшыртуга аеруча | 17.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында “Татарстан Республикасында укытучыларның квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан әзерләү турында”гы мәсьәләне карау (Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты базасында, Казан шәһәре).<br>17.2. КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе комитеты утырышында баланың мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүе өчен ата-ана түләве күләме турындагы мәсьәләне карау. | 2015 елның ноябре<br><br><br><br><br><br><br><br><br>2016 елның<br>I кварталы | Вәлиев Р.И.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | зур игътибар бирергә кирәк. Мәктәпләр арасындагы рейтинг әлеге үсешкә этәргеч бирәчәк. Ул, үз чиратында, объектив, нигезле һәм һәркемгә аңлаешлы, ачык булырга тиеш. | | | фракциясе әгъзалары |
| 18. | Югары уку йортларыбыз алдында да җитди бурычлар тора. Алар арасында уку-укыту процессының сыйфатын яхшырту, мәгариф программаларының даими яңартылып торуы, предприятиеләр белән бергәләп эшчәнлек алып бару, әйдәүче галимнәрне һәм гамәли хезмәткәрләрне укыту эшенә җәлеп итү.<br>Моннан тыш, мәктәптән тыш эшне һәм техник юнәлештәге өстәмә белем бирү системасын үстерү дә мөһим. Монда шулай ук һөнәри билгеләнешкә басым ясарга кирәк.<br>Әлеге юнәлештә Стратегик инициативалар агентлыгы белән берлектә республикада балалар технопарклары төзү яхшы этәргеч булачак. | 18.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында “Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирү системасы турында”гы мәсьәләне карау. | 2015 елның октябре | Вәлиев Р.И. |
| 19. | Тулаем алганда, безнең төп бурычыбыз – сәләтле кешеләргә яшәү һәм иҗат итү, һәр баланың талантын күреп ала белү һәм аларны үстерү өчен шартлар булдыру. “Талантлар белән стратегик идарә итү” дип аталган дәүләт программасы шуңа юнәлтелгән.<br>Креатив индустрияләр булдыру республикага иҗади яшьләрне җәлеп итүдә ярдәм булачак. Алар, үз | 19.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында “Талантлар белән стратегик идарә итү” дәүләт программасы турында”гы мәсьәләне карау. | 2016 елның ноябре | Вәлиев Р.И. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | чиратында, кече бизнеска, заманча шәһәр үсешенә көчле этәргеч бирәчәк. | | | |
| 20. | Тормыш өчен уңайлы мохит тудыруда гражданнарның торак шартларын, торакның сыйфатын яхшырту, аларның торак белән тәэмин ителешен кайгырту мөһим факторлар булып тора. Коммерциячел нигездә һәм шәхси йортлар төзүгә кызыксындыруны арттырырга кирәк. | 20.1. “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең күчмә утырышында “Республикада торак программаларын гамәлгә ашыру проблемалары һәм перспективалары (эконом классы, азкатлы торак, арендага бирелгән торак һ.б.)” мәсьәләсен карау. | 2016 елның июне | Борһанов Р.Т. |
| 21. | Бүгенге көндә республика буенча 23 мең кешене авария хәлендәге торак йортлардан күчерү таләп ителә. Әлеге мәсьәлә Казан, Зеленодольск һәм Чистай шәһәрләрендә аеруча кискен тора.<br>Хөкүмәт һәм муниципалитетлар әлеге программаны үтәүне тәэмин итәргә тиеш. | 21.1. “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең күчмә утырышында “Республикада гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программаларын гамәлгә ашыру йомгаклары һәм проблемалары” мәсьәләсен карау.<br>21.2. “Татарстан Республикасында авария хәлендәге торак проблемасын хәл итү юллары” темасына түгәрәк өстәл. | 2016 елның сентябре<br><br>2016 елның I кварталы | Борһанов Р.Т.<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе әгъзалары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 22. | Күпбалалы гаиләләргә бүлеп биреләчәк җир кишәрлекләренең инфраструктура ягыннан тәэмин ителүе актуаль бурыч булып кала.<br>Кайбер районнар әлеге мәсьәләне хәл итүнең механизмнарын уйлап таба. Мисал өчен, Алабугада бу мәсьәлә Торакны ипотека нигезендә кредитка бирү агентлыгы программасы нигезендә хәл ителә.<br>Башкалабыз җитәкчеләренә әлеге уңай тәҗрибәне исәпкә алырга киңәш итәм. Федераль һәм республика акчаларына өметләнеп, көтеп утырырга кирәкми. | 22.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында “Күпбалалы гаиләләргә бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләре инфраструктурасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында”гы мәсьәләне карау. | 2016 елның марты | Һадиев Т.Г. |
| 23. | Без киләчәктә дә халык өчен уңайлы җәмәгать урыннары булдыру буенча эшне су объектларын төзекләндерү рәвешендә дәвам итәчәкбез.<br>Гамәлдәге канализация чистарткыч корылмаларының ышанычлы һәм нәтиҗәле эшләве республиканың санитария һәм экология ягыннан иминлеген тәэмин итүнең бер өлеше булып тора.<br>Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына, муниципалитетлар белән бергәләп, аларны төзекләндерү һәм реконструкцияләүне тәэмин итәргә кирәк. | 23.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су саклау зоналарының һәм су объектларының яр буе саклау полосаларының экологик торышы турында”гы мәсьәләне карау. | 2016 елның июне | Һадиев Т.Г. |
| 24. | Уңайлы тормыш шартлары булдыруда әйләнә-тирә мохитнең чисталыгын тәэмин итү көннән-көн әһәмиятлерәк була бара. Гражданнарның экологик иминлеген тәэмин итү, табигать | 24.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында “Татарстан Республикасында урманнарны саклау, яклау, | 2016 елның апреле | Һадиев Т.Г. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ресурсларын саклап калу һәм алардан рациональ файдалану әлеге өлкәдә өстенлекле бурыч булып тора. Республикада бер генә проект та төпле экологик экспертизадан башка тормышка ашырылмый. Экология басымын эзлекле киметү мөмкинлеген бирүче чараларны тормышка ашыруны дәвам итәргә кирәк.<br>Төрле категориядәге калдыкларның күләме арту мәсьәләсе бүгенге көндә аеруча кискен тора. Гамәлдәге полигоннарга йөкләнеш елдан-ел арта бара, әмма шул ук вакытта рөхсәтсез чүплекләр саны да кимеми. Бүген үк калдыклар белән эшләүнең нәтиҗәле системасын булдыру зарур. | җитештерү, шулай ук әлеге максатларга юнәлдерелгән бюджет чараларын нәтиҗәле файдалану өлешендә законнарның үтәлеше турында"гы мәсьәләне карау.<br>24.2. КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе утырышында "Татарстан Республикасында санитар зоналар һәм калдыкларны юкка чыгару, эшкәртү һәм зарарсызландыру системасын проектлаштыру һәм төзү зарурлыгы турында"гы мәсьәләне карау. | 2016 елның<br>I кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе әгъзалары |
| | | 24.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында "Әйләнә-тирә мохитне җитештерү һәм куллану калдыкларының тискәре йогынтысыннан саклау өлкәсендәге законнарның үтәлеше турында"гы мәсьәләне карау. | 2016 елның мае | Һадиев Т.Г. |
| 25. | Югары технологияле медицина үзәкләре төзү һәм клиникаларны заманча җиһазландыру белән беррәттән, авыруларны алдан кисәтү, диспансеризация узу, халыкка беренчел медицина ярдәме күрсәтү шәһәрдә дә, авылда да өстенлекле юнәлешләр булып кала. | 25.1. "2014 һәм 2015 елларда махсуслаштырылган, югары технологиялене дә кертеп, медицина ярдәме күрсәтүгә, шулай ук сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү чараларына юнәлдерелгән бюджет чараларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану турында" темасына "түгәрәк өстәл". | 2015 елның<br>IV кварталы | Якунин Л.А. |
| | Гомумтабиблык практикасы челтәрен үстерү, районара үзәкләрне ныклы лаборатория һәм диагностика базасы, квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү, кыйммәтле технологияләрне һәм дистанцион консультация уздыруны да | 25.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы | 2015 елның декабре | Захарова С.М. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кертеп, заманча тикшеренүләр үткәрү буенча эшне дәвам итәргә кирәк. | комиссиясенең уртак утырышында “Татарстан Республикасында медицина реабилитациясе системасы үсеше турында”гы мәсьәләне карау *(Түбән Кама район үзәк хастаханәсенең консультатив поликлиникасы базасында).* | | |
| 26. | Ел саен Татарстанда, югары технологияләр кулланып, 20 меңнән артык операция ясала. Аларның нәтиҗәлелеге авыруны алга таба тернәкләндерүдән һәм реабилитацияләүдән гыйбарәт. Шуның нәтиҗәсендә, мәсәлән, миокард инфаркты кичергән авыруларның 80 проценты гадәттәге яшәү рәвешенә кайта. Шуларны исәпкә алып, республикада заманча яңа реабилитация үзәкләре эшли башларга тиеш. | 26.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында “Татарстан Республикасында медицина реабилитациясе системасы үсеше турында”гы мәсьәләне карау. | 2016 елның марты | Захарова С.М. |
| 27. | Хәзерге вакытта дәүләтнеке булмаган сәламәтлек саклау секторы актив үсештә. Республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгына шәхси һәм дәүләт медицина оешмалары эшен халык мәнфәгатьләрен күздә тотып оештыру мәгъкуль.<br>Шул ук вакытта сыйфатлы хезмәт күрсәтү һәм пациентлар мәнфәгатьләрен беренче урынга кую һәрбер медицина хезмәткәренең төп бурычы булып тора. | 27.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында “Социаль өлкәдә дәүләти-хосусый партнерлык турындагы законнарны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 29 июнендәге 39 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты карарын үтәү хакында”гы мәсьәләне карау. | 2016 елның июне | Захарова С.М. |
| 28. | Төзелгән спорт инфраструктурасының массакүләм спорт үсешенә хезмәт итүе бик мөһим.<br>Безнең бурыч – системалы рәвештә | 28.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында “Татарстан Республикасында массакүләм спортны үстерү турында”гы | 2016 елның октябре | Захарова С.М. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүче халыкның санын арттыру. Шул максаттан чыгып, без яңа спорт объектларын, беренче чиратта, муниципаль районнарда универсаль мәйданчыклар төзүне дәвам итәчәкбез, ГТО комплексын кертү һәм популярлаштыру эшен активлаштырачакбыз. | мәсьәләне карау. | | |
| 29. | Гаилә институтын ныгыту дәүләтнең төп бурычы булып тора. Бүген республикада планлы рәвештә алып барыла торган эш һәм тормышка ашырыла торган социаль программалар берничә ел рәттән туучылар саны артуга китерә. Өч, дүрт һәм биш балалы гаиләләр саны арта. Безнең бурыч – булдыра алганча андый гаиләләргә ярдәм итү. | 29.1. “Гаилә һәм гаилә кыйммәтләре. Гаилә һәм балалар мәнфәгатьләрендә дәүләтнең һәм җәмгыятьнең социаль партнерлыгы” темасына “түгәрәк өстәл”. | 2015 елның ноябре | Воропаева Т.В. |
| 30. | Никахны өзү тәртибенең гадилеген закон нигезендә юкка чыгарырга кирәк. | 30.1. Никахны өзү тәртибенең гадилеген юкка чыгару өлешендә Россия Федерациясе Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы өстендә эшләү. | 2015 елның IV кварталы | Захарова С.М. |
| 31. | Дәүләт һәм муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәрвакыттагыча актуаль мәсьәлә булып кала.<br>Беренче чиратта муниципалитетларның гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актлары күп булу борчу тудыра. Бу исә белгечләрнең хокукый белеме түбән | 31.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында муниципаль хокукый актлар кабул итү өлешендә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары эше турындагы контроль мәсьәләне кабат карау. | 2016 елның IV кварталы | Хәбибуллин А.Г. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Хөкүмәткә ел саен муниципаль берәмлекләр өчен хокукый белемле хезмәткәрләр әзерләү буенча максатчан төркемнәр булдыру һәм квалификация күтәрү эшен оештырырга кирәк. | 31.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең квалификациясен планлы рәвештә күтәрү. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| | | 31.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр өчен өйрәтү семинарларында һәм лекцияләрендә катнашулары. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе |
| | | 31.4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең “Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре” исеменә еллык республика конкурсында катнашулары. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |